**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **20 ноябрь 2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
Районы Туйкә авыл җирлеге составына керүче
Карамалы-Елга авылында 2020 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Карамалы-Елга авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Туйкә авыл җирлеге Карамалы-Елга торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (Бер мең) сум күләмендә, 2 группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 500 (Биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

-Карамалы – Елга авылы зират коймасын алмаштыру (материаллар сатып алу, эшләр өчен килешү буенча түләү);

- Карамалы-Елга авылы Сәйдәшев урамы исеме язылган күрсәткечләр сатып алу;
- Карамалы-Елга авылы юлларын кардан чистарту;
- үзәкләштерелгән чыганаклардан эчә торган суны анализлау: “Карамал башы " чишмәсе;
- Карамалы-Елга авылында «Авыл бәйрәме»н үткәрү буенча хезмәт күрсәтү, бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;
- Карамалы-Елга авылы Сәйдәшев урамы юлынын техник паспортын ясату;
- Карамалы-Елга авылы зиратынын җир кишәрлеген ызанлау; җирләрнең категорияләрен үзгәртү.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Туйкә авыл җирлеге Башлыгы Закирова Р.Р.